Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге Советы

**КАРАР № № 1**

Олы Әшнәк ав. 2016 елның 1 феврале

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 пунктының «в», Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Олы Әшнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Олы Әшнәк авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә түбәндәге сораулар буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итәргә:

2016 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш балигъ булган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?

- Кече Әшнәк авылында чишмәгә басма салу – 30000 сум;
- Олы Әшнәк авылы, Садовая урамына сумлык күпер төзү – 40000 сум;
- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тоту:

1) урамнарның йөрү өлешен кышкы чорда карап тоту (кар чистарту) 6000 сум

ЭЙЕ ЮК.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28а йорт; Кече Әшнәк авылы, Кызыл Армия урамы, 32а йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан

Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге Башлыгы Р.А.Хөснетдинова